**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**САРМАНОВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ**
**2025 ел, 16 декабрь**

**КАРАР**
**№ 12**

Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 24 апрелендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 декаберендәге 994 номерлы карары, Сарман муниципаль районы «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Петровский Завод авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәте өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 24 апрелендәге 1 номерлы карарына (Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 8 номерлы, 2018 елның 21 ноябрендәге 27 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендагы 6 номерлы, 2020 елнын 14 декабрендагы 15 номерлы, 2024 елнын 20 июнендагы 9 номерлы, 2025 елнын 30 апрелендагы 5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәре:

| Вазифа исеме | Айлык акчалата түләү, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 10 төркем* | 11төркем* | 12 төркем* |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 27 601 | 25 401 | 23 201 |

*муниципаль берәмлек «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны булдыруның нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган хезмәт өчен түләү төркеме, аның составына муниципаль берәмлек керә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 майдан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Р.Нуртдинов